**СОВЕТ РОЖДЕСТВЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422631с.Дятлово,
ул. Юности, д.1
тел: 4-74-98

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ РОЖДЕСТВЕНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422631 Дятлово авылы,
Яшьлек урамы, 1 нчы йорт,
тел: 4-74-98

2020 елның 22 июне 209 номер

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Рождествено авыл җирлеге советы дүртенче чакырылыш депутатлар сайлауларны билгеләү турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2007 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы 105 статьясындагы 1 өлеше белән, “Рождествено авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 13 статьясына таянып, Лаеш муниципаль районы Рождествено авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Рождествено авыл җирлеге Советына дүртенче чакырылыш депутатлар сайлауларын 2020 елның 13 сентябренә билгеләргә.

2. Әлеге карарны «Кама ягы» («Камская новь») район газетасында, кабул ителгәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча, махсус мәгълүмат стендларында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы һәм Интернет-телекоммуникация челтәрендә Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча урнаштырырга(халыкка җиткерергә).

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Рождествено**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **С.М. Гуцу**